ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ МАЙНА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

СОВЕТ МАЙНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**КАРАР** Югары Тат.Майнасы авылы **РЕШЕНИЕ**

18.01.2019 № 88

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Майна авыл җирлеге**
**муниципаль берәмлегендә муниципаль**
**хезмәткәрләрнең яллаучы вәкил (эш бирүче)**
**тарафыннан бер кеше кулындагы**
**башкарма орган сыйфатында**
**коммерциячел булмаган**
**оешмалар (сәяси партиядән тыш)**
**белән идарә итүдә бушлай нигездә катнашуга яки аларның**
**коллегиаль идарәсе органнары составына**
**керергә рөхсәт алу тәртибе**
**турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Тиешле законнарга, шул исәптән “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы 02.03.2007, 25-ФЗ санлы Федераль закон, “Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 29.07.2017 ел, 217-ФЗ санлы Федераль закон нигезләмәләренә туры китерү максатында

**Майна авыл жирлеге Советы карар бирде:**

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең яллаучы вәкил (эш бирүче) тарафыннан бер кеше кулындагы башкарма орган

сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итү дә бушлай нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарәсе органнары составына керергә рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәгә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге Советы карары белән расланган түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешне кертергә:

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль

хезмәткәрләрнең яллаучы вәкил (эш бирүче) тарафыннан бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бушлай нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарәсе органнары составына керергә (моннан соң – Нигезләмә, муниципаль хезмәткәрләр) рөхсәт алу тәртибе турындагы әлеге Нигезләмә“ Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы 2 март, 2007 ел, 25-ФЗ санлы Федераль законның 14 маддәсе, 1 нче өлеше, 3 нче пункты нигезендә эшләнде һәм муниципаль хезмәткәрләрнең яллаучы вәкиленнән (эш бирүчедән) бушлай нигездә җәмәгать оешмасына, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларына, күчемсез милек хуҗалары ширкәтләренә (моннан соң муниципаль хезмәткәрләрнең бушлай нигездә комерциячел булмаган оешмага идарә итүдә катнашу) идарә итүдә катнашуга рөхсәт алу процедурасын регламентлый.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге Советының 17 нче ноябрь, 2018 ел, 76 нчы санлы карарын көчен югалткан, дип санарга.

3. Әлеге карарны Майна авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат тактасында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Майна авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Р.Н.Гафиятуллин**